| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **БОЕРЫК**

02.02.2023 Баулы шәһәре №14

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлегендә җирләү
буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән
исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ

1. 1-нче һәм 2-нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Баулы шәһәрендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2023 елның 1 февраленнән 7793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм сайтта (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Н.И. Шәрифуллин

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге Башкарма комитетының
2023 елның 02 февралендәге
14 номерлы карарына
1нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасының
“Баулы шәһәре” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәт | Хезмәт бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Җирләү өчен табутны һәм кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3880,70 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1845,09 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2067,69 |
| | Барлыгы: | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге Башкарма комитетының
2023 елның 02 февралендәге
14 номерлы карарына
2нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасының
“Баулы шәһәре” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр исемлеге бәясе

| № п/п | Хезмәт | Хезмәт бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | – |
| 2. | Кәфенләү | 1100 |
| 3. | Җирләү өчен табутны һәм кирәкле башка предметларны бирү һәм китерү | 3280,70 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 1545,09 |
| 5. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1867,69 |
| | Барлыгы: | 7793,48 |